**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 7 маендагы 1393 номерлы карары**

## 2025 елның җәйге чорында Казан шәһәренең су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар оештыру турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр гомерен саклау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 30 июнендәге 1591 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2006 елның 24 маендагы 982 номерлы "Казан шәһәре пляжлары турында"гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 17 июнендәге 2484 номерлы «Су объектлары һәм Казан шәһәре территориясендә урнашкан гомуми кулланыштагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлар өчен файдалану кагыйдәләре турында»гы карары, Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2020 елның 30 сентябрендәге 732 номерлы «Россия Федерациясендә пляжлардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында»гы әмере нигезендә, Казан шәһәре территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерләрен саклау һәм куркынычсыз ялын оештыру максатыннан:

1. **Карар бирәм:**

1.1. 2025 елга Казан шәһәре пляжлары һәм су янында оештырылган ял итү урыннары исемлеген әлеге карарга кушымта нигезендә расларга;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Гражданнарны яклау идарәсенә (С.Х.Чанкин):

1.2.1. оешмалар белән түбәндәге эшләрне башкаруга контрактлар төзүне оештырырга:

- пляжларда һәм су янында ял итү урыннарында коткару һәм медицина пунктларын карап тоту һәм аларның эшен оештыру буенча хезмәтләр күрсәтү;

- пляжларның төпләрен водолазлар ярдәмендә һәм су янында кешеләрнең ял итү урыннарын тикшерү;

- пляжларны ачу алдыннан суга һәм туфракка беренчел анализлар үткәрү.

Тикшерү нәтиҗәләрен пляжларны эксплуатацияли торган оешмаларга тапшырырга;

1.2.2. 2025 елның 1 июненнән 2025 елның 1 сентябренә кадәрге чорда Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе, пляжлар хуҗалары һәм арендачылар белән берлектә пляжларда һәм су янында оештырылган ял итү урыннарында ведомство һәм җәмәгать коткару постларын булдырырга, «Комсомол күле» һәм «Зур Аккош күле» пляжларында коткаручылар өчен икешәр пост оештырырга.

Коткаручыларның пляжлардагы эш режимын көн саен – 09.00 дән 20.00 гә кадәр, «Түбән Заречье» пляжында – 09.00 дән 21.00 гә кадәр, «Комсомол күле» пляжында – 08.00 дән 20.00 гә кадәр, «Комсомол күле» ял итү урынында 09.00 дән 20.00 гә кадәр дип билгеләргә, «Зәңгәр күл» ял итү урынында ике коткаручы һәм аларның эш режимын 10.00 дән 19.00 гә кадәр билгеләргә;

1.2.3. кирәк булган очракта, тиешле мәгълүмат такталары урнаштырып, коену өчен су объектларыннан файдалануны, кече суднолардан, шул исәптән гидроцикллардан һәм башка техника чараларыннан файдалануны чикләү яки туктатып тору турында билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә;

1.2.4. суда үз-үзеңне тотуның куркынычсызлык кагыйдәләре һәм Казан шәһәренең су объектларында су коенуны чикләү турында халыкка мәгълүмат җиткерүне оештырырга;

1.2.5. Казан шәһәре пляжларында һәм су янында оештырылган ял итү урыннарында коткару һәм медицина постларын карап тоту буенча хезмәт күрсәтүгә контрактның үтәлешен, коткаручыларның эшен контрольдә тотуны оештырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясенә (Р.Х.Шәмсетдинов), Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясенә (А.И.Салихов), Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү

районнары администрациясенә (В.В.Жаворонков), Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясенә (Р.Р.Фәтхетдинов), Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсенә (А.И.Абзалов):

1.3.1. 2025 елның 25 маена кадәр җаваплы оешмалар тарафыннан пляжларны һәм су янында оештырылган ял итү урыннарын коену сезонына әзерләү буенча кирәкле чаралар үткәрүне тәэмин итәргә;

1.3.2. 2025 елның 20 маена кадәр пляжларны һәм су янында оештырылган ял итү урыннарын коену сезонына әзерләүне һәм карап тотуны тәэмин итә торган җаваплы оешмалар, «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалардан килгән зыяннарны бетерү буенча министрлыкның Татарстан Республикасы буенча Кече суднолар дәүләт инспекциясе үзәге» федераль казна учреждениесе, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Гражданнарны яклау идарәсе вәкилләре катнашында, территориягә мөнәсәбәтле рәвештә, пляжларны һәм су янында оештырылган ял итү урыннарын кабул итеп алу буенча район комиссияләре төзергә;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов), Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитетына (Л.З.Гарипов), Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына (А.Р.Заһидуллина):

1.4.1. 2025 елның 21 маена кадәр Казан шәһәренең гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә учреждениеләрендә балаларның су объектларында үз-үзләрен тоту кагыйдәләре, су коенганда куркынычсызлык чаралары, батучыларга ярдәм күрсәтү алымнары һәм ысуллары буенча дәресләр үткәрергә;

1.4.2. 2025 елның 1 июненнән 2025 елның 1 сентябренә кадәрге чорда балалар сәламәтләндерү һәм спорт лагерьларында йөзәргә өйрәтү, коену кагыйдәләрен һәм суда куркынычсызлык чараларын аңлату буенча даими эш алып барырга;

1.4.3. чираттагы смена башланырга биш көн кала балалар сәламәтләндерү һәм спорт лагерьларында суда куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча җаваплы җитәкчеләрне һәм хезмәткәрләрне әзерләүне оештырырга;

1.5. муниципаль пляжларны, балалар һәм спорт лагерьларында су коену урыннарын эксплуатацияли торган җаваплы оешмаларга пляжларны тиешенчә карап тотуны һәм сулыклардагы суның сыйфатына җитештерү лаборатория контроле уздыруны тәэмин итәргә, су объектын рекреация максатларында

файдалануга санитар-эпидемиологик бәяләмә булган очракта коенуны рөхсәт итәргә;

1.6. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 15 маендагы 2053 номерлы «2024 елның җәйге чорында Казан шәһәренең су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар оештыру турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга;

1.7. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров):

2.1.1. муниципаль пляжларда куркынычсызлыкны һәм хокук тәртибен саклауны оештырырга, шул исәптән рөхсәтсез сәүдә итүне, табигатьне саклау турындагы законнарны бозуны, спиртлы эчемлекләр эчү очракларын кисәтүне тәэмин итәргә, хокук бозучыларга карата законнар нигезендә чаралар күрергә;

2.1.2. су коену сезоны чорында муниципаль пляжларны полиция нарядлары тарафыннан патрульлек итүне көн саен – 15.00 дән 20.00 гә кадәр, ял һәм бәйрәм көннәрендә 9.00 дән 22.00 гә кадәр оештырырга;

2.2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсенә (В.С.Филатов) 2025 елның 1 июненнән 2025 елның 1 сентябренә кадәрге чорда ял итүчеләргә медицина хезмәте күрсәтүне контрольдә тотуны оештырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 7 маендагы
1393 номерлы карарына
кушымта

**2025 елга Казан шәһәре пляжлары һәм**
**су янында оештырылган ял итү урыннары исемлеге**

| № т/б | Атамасы | Урнашкан урыны | Район | Җаваплы учреждение |
|---|---|---|---|---|
| 1 | «Локомотив» пляжы | Идел елгасы, Порт дамбасы | Вахитов районы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе |
| 2 | «Түбән Заречье» пляжы | Казансу елгасы, Заречье дамбасы | Киров районы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе |
| 3 | «Тирән күл» пляжы | Тирән күл, Тирән күл территориясе | Киров районы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе |
| 4 | «Зур Аккош күле» пляжы | Зур Аккош күле, Аккош күлләре территориясе | Киров районы | «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 5 | «Комсомол» пляжы | Комсомол күле, Дербышки торак массивы | Совет районы | «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | муниципаль бюджет учреждениесе |
| 6 | «Зөбәрҗәт күл» оештырылган ял итү урыны | Зөбәрҗәт күл, Юдино торак массивы | Киров районы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе |
| 7 | «Кече Аккош күле» оештырылган ял итү урыны | Кече Аккош күле, Аккош күлләре территориясе | Киров районы | «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 8 | «Җиңү паркы» оештырылган ял итү урыны | Җиңү паркындагы күл яры | Яңа Савин районы | «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 9 | «Зур Зәңгәр күл» оештырылган ял итү урыны | Зур Зәңгәр күл | Яңа Савин районы | «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 10 | «Күзәмәт» оештырылган ял итү урыны | Идел елгасы | Киров районы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе |